ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## "Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 24 декабрендә
кабул ителде

### 1 статья

"Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында" 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5; Ватаным Татарстан, 2014, 21 ноябрь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяда:
а) 3 пунктта "һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының $97^{1}$ статьясы нигезендә депутат мандаты тапшырылган кандидатларның республика исемлеге составында сайланган һәр депутатка" сүзләрен төшереп калдырырга;
б) $3^{1}$ пунктның беренче абзацында "шулай ук Татарстан Республикасы Сайлау кодексының $97^{1}$ статьясы нигезендә депутат мандаты тапшырылган кандидатларның республика исемлеге составында сайланган" сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 7 статьяның 3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

3) $7^{1}$ статьяда:
а) 2 пунктта "Татарстан Республикасы Сайлау кодексының $97^{1}$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатларның республика исемлекләре составында сайланган депутатлар," сүзләрен төшереп калдырырга;
б) 7 пунктның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

4) $10^{1}$ статьяда:
а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Депутатның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр Россия Федерациясе Президенты раслаган белешмә формасы буенча тапшырыла.";

б) 5 пунктның икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Депутат әлеге статьяның 1 пункты нигезендә белешмәләр тапшырган көннән алып бер ай эчендә төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшыра ала.";

5) 1 нче һәм 2 нче кушымталарны үз көчләрен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 елның 16 гыйнвары
№ 2-ТРЗ